ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 22.05.2023 КАРАР
676

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне килештерү буенча комиссия булдыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү, килештерү, раслау, гамәлдә булу срокларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү, файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү үзенчәлекләре турында» 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы карары, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 11 апрелендә расланган 501 номерлы карары нигезендә расланган, объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне килештерү буенча комиссия составын расларга (1 нче кушымта).
2. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне килештерү буенча комиссия объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында җирле үзидарә органына гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.
3. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне килештерү буенча комиссия түбәндәгеләрне билгели:
   3.1. Капиталь төзелеш объекты җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын төзү өчен рөхсәт бирелгән көнгә билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга куелган таләпләргә туры килмәве яки линияле объектны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау очрагында, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә туры килмәве (линияле объектны төзү, үзгәртеп кору өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), территорияне планлаштыру проекты белән билгеләнгән таләпләргә, урнаштыру өчен җир

кишәрлеге төзү таләп ителми торган линияле объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

3.2. РФ ШрК 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә, капиталь төзелеш объектының мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының параметрлары проект документларына туры килмәгән очракта;

3.3. Капиталь төзелеш объектының төзелешкә бирелгән рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, РФ ШрК 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә, капиталь төзелеш объектының мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш;

3.4. Әгәр күрсәтелгән чикләүләр РФ ШрК 51 статьясындагы 7 өлешенең 9 пунктында каралган очракларда, кабул ителгән территорияне файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яисә үзгәртү турындагы карарда каралган һәм аның урнашуына бәйле рәвештә территорияне файдалануның махсус шартлары булган зона урнаштырылган яки үзгәртелгән төзелеп килүче, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объекты файдалануга кертелмәгән очраклардан тыш, капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән файдалану өчен рөхсәт ителгән һәм (яки) Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирелгән көнгә билгеләнгән чикләүләргә туры килмәве, шулай ук Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 11 апрелендәге 501 номерлы карары нигезендә расланган, объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.9.1 пунктындагы "г"-"ж" пунктчаларында, 2.10.1 пунктында каралган документларның барлыгын тикшерә.

4. Әлеге карарның 3 пунктында каралган параметрларның туры килүенә объектны караганнан соң, комиссия рәисе урынбасары 1 эш көне эчендә килештерү турында яки объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча килештерүдән баш тарту турында акт төзи.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш..

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00FBD291B1574C09AAA1CBD7F6C923D025
Владелец: Исланов Роман Леонидович
Действителен с 14.03.2023 до 06.06.2024

Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
22.05.2023 676 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне килештерү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары |
| Комиссия рәисе урынбасары | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы |
| Члены комиссии: | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасары |
| | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының орден-рөхсәт секторы мөдире |
| | «ТР Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы төзелеш департаменты» МКУ директоры |